| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 сентябрь № 670

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 ел, 20 май, ТРЗ-26 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 24 сентябрь, 798 нче карары белән расланган Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 ел, 20 май, ТРЗ-26 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 24 сентябрь, 798 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 февраль, 66 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

2.9 нчы пунктта «Утырышларның көн тәртибен» сүзләреннән соң «аларны үткәрү көнен, вакытын, » сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 2.15.1 нче пункт өстәргә:

«2.15.1. Шәхеснең, гаиләнең һәм балигъ булмаганнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм горурлыгына, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, конституциягә һәм дәүләт иминлегенә, кешелекнең тынычлыгына һәм иминлегенә, шулай ук иҗтимагый куркынычсызлыкка каршы зур булмаган авырлыктагы һәм уртача авырлыктагы җинаятьләр кылган өчен хөкемгә тартылган булган затларны (стационар шартларында психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына законсыз рәвештә салу һәм яла ягу очракларыннан тыш), әлеге җинаятьләрне кылуда гаепләнгәннәргә мөнәсәбәтле җинаять тикшерүе акламый торган нигезләр буенча туктатылган затларны (суд карары буенча тиешле эшчәнлек төрендә катнашу хокукыннан мәхрүм ителгән затлардан тыш) педагогик эшчәнлектә, эшмәкәрлек эшчәнлегендә һәм (яки) балигъ булмаганнарга белем бирү,

тәрбия бирү, аларны үстерү, аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру, медицина ярдәме белән тәэмин итү, социаль яклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге, балигъ булмаганнар катнашында балалар-яшүсмерләр спорты, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге хезмәт эшчәнлегендә катнаштыру яки катнаштырмау турында Республика комиссиясенең карарлары, кылынган җинаятьнең төрен һәм авырлык дәрәҗәсен, аны кылган мизгелдән үткән вакытны, гаепнең формасын, кылынган гамәлнең закон нигезендә аеруча авыр булмаган җинаятьләр категориясенә кертелүен, шәхесне тасвирлый торган шартларны, шул исәптән затның җинаять кылганнан соң үз-үзен тотышын, хезмәт вазыйфаларын үтәүгә мөнәсәбәтен исәпкә алып, шулай ук балигъ булмаганнарның гомеренә, сәламәтлегенә һәм әхлаклылыгына аерым бер затның куркыныч тудыру-тудырмавын билгеләргә мөмкинлек бирүче башка факторларны исәпкә алып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы тарафыннан төзелгән балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең хөкемгә тартылган булган затларны педагогик эшчәнлектә, эшмәкәрлек эшчәнлегендә һәм (яки) балигъ булмаганнарга белем бирү, тәрбия бирү, аларны үстерү, аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру, медицина ярдәме белән тәэмин итү, социаль яклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендәге, балигъ булмаганнар катнашында балалар-яшүсмерләр спорты, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге хезмәт эшчәнлегендә катнаштыру яки катнаштырмау турында карар кабул итү кагыйдәләрен, шулай ук әлеге карар формаларын раслау хакында» 2015 ел, 5 август, 796 нчы карары белән расланган тәртиптә кабул ителә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән карарлар аларны кабул иткән көндә республика комиссиясе тарафыннан мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

Әлеге карарлар исәп-хисап журналында теркәлә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

карарны теркәү саны һәм көне;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, яшәү урыны (яшәү урыны буенча теркәлү турында, булмаган очракта – гариза бирүче даими яки күбесенчә яшәгән урын турында белешмәләрне күрсәтеп) яки гариза бирүче вәкиленең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм яшәү урыны;

Республика комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карар нигезендә балигъ булмаганнар катнашындагы эшчәнлектә гариза бирүчене катнаштыру яки катнаштырмау турында мәгълүматлар;

Республика комиссиясе утырышы беркетмәсенең саны һәм көне;

гариза бирүчегә яки аның вәкиленә кул куйдырып карарны тапшыру көне турында яисә гариза бирүче яки аның вәкиле тарафыннан күрсәтелгән адрес буенча, тапшыру турында хәбәр итеп, карарны заказлы хат белән җибәрү көне хакында белешмәләр.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\670.docx